ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18 апрель 2017 ел. № 2342

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру тәртибе турында нигезнамәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләти җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Расларга:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру тәртибе турында нигезнамәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру хокукына электрон аукцион оештыру һәм үткәрү турында нигезнамәне, 2 нче кушымтада каралганча.

2. Вәкаләтле орган итеп:

1) сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру хокукына аукцион оештыру һәм үткәрү буенча Башкарма комитетның муниципаль заказ бүлеген;

2) сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру хокукына килешүләр төзү буенча чаралар оештыру һәм аларның үтәлешен контрольдә тоту буенча Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсен билгеләргә.

3. Үз көчен югалткан дип танырга:

1) Башкарма комитетның «Шәһәр территориясендә язгы-җәйге чорда ваклап сату челтәрен һәм тиз хезмәт күрсәтүче җәмәгать туклануы предприятиеләрен (җәйге кафелар) урнаштыру тәртибе турында» 2008 елның

14 маендагы 1350 нче карары;

2) Башкарма комитетның «Шәһәр территориясендә язгы-җәйге чорда ваклап сату челтәрен һәм тиз хезмәт күрсәтүче җәмәгать туклануы предприятиеләрен (җәйге кафелар) урнаштыру тәртибе турында» 2006 елның 24 апрелендәге 1121 нче карары.

4. Әлеге карарны «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керүне билгеләргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага, Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга, Башкарма комитетның муниципаль заказ бүлеге башлыгы А.И. Вилдановка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2017 елның 18 апрелендәге
2342 нче карарына
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру тәртибе турында
нигезнамә

## 1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге нигезнамә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләти җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә, сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыруны тәртипкә салу, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге халкына сәүдә хезмәте күрсәтүне оештыру һәм аның сыйфатын яхшырту өчен шартлар тудыру максатында эшләнде.

2. Әлеге нигезнамә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру өчен нигезләрне, аның тәртибен билгели һәм киосклар, павильоннар урнаштыру белән бәйле мөнәсәбәтләргә кагылмый.

3. Сезонлы стационар булмаган сәүдә объектлары һәм җәмәгать туклануы объектлары күчемсез милек булып саналмый һәм техник исәпкә кертелергә тиеш түгел, аларга хокук күчемсез милеккә һәм аңа бәйле килешүләр төзүгә хокукларның Бердәм дәүләт реестрында теркәлергә тиеш түгел.

4. Әлеге нигезнамәдә күздә тотылган таләпләр вакытлыча характерга ия бәйрәм, иҗтимагый-сәяси, мәдәни-массакүләм һәм спорт-массакүләм чаралары үткәргәндә, ярминкәләр, күргәзмә-ярминкәләр үткәргәндә стационар булмаган сәүдә объектлары урнаштыру белән бәйле мөнәсәбәтләргә кагылмый.

## 2 бүлек. Төп төшенчәләр һәм аларның билгеләмәләре

5. Әлеге нигезнамәдә түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

а) ваклап сату – шәхсән, гаиләдә, йортта һәм башка максатларда файдалану өчен товарлар сатып алу һәм сату белән бәйле, эшмәкәрлек эшчәнлеге белән бәйле булмаган сәүдә эшчәнлеге төре;

б) сәүдә субъекты – сәүдә белән шөгыльләнүче һәм билгеләнгән тәртиптә теркәлгән юридик зат яки шәхси эшмәкәр;

в) сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру схемасы – Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) тарафыннан

эшләнгән һәм расланган, сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын, җәмәгать туклануы объектларын һәм аларда сатыла, хезмәтләр күрсәтә торган товарлар төркемен урнаштыру урыннарын билгеләүче хокукый акт;

г) сезонлы стационар булмаган сәүдә объекты – капиталь төзелеш объекты һәм күчемсез милек булып саналмаган, инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташкан яки тоташмаган (технологик кушылу) булуга бәйсез рәвештә җиргә тоташтырылмаган корылма яки конструкциядән гыйбарәт сәүдә объекты, шул исәптән ел сезоннарында урнаштырыла һәм күчереп йөртелә торган корылма (урамга ташып сәүдә итү өчен күчереп йөртелә торган чаралар, бакча культуралары мәйданчыгы, чыршы базарлары һәм башкалар);

д) сәүдә автоматы – сатучы катнашыннан башка товарлар сату өчен билгеләнгән техник корылма яки конструкция;

е) бакча культуралары мәйданчыгы – бакча культуралары сату өчен билгеләнгән махсус җиһазландырылган конструкция;

ж) чыршы базары – табигый ылыслы агачлар сату өчен мәйданчыктан гыйбарәт махсус җиһазландырылган вакытлы конструкция;

з) сезонлы кафелар – җәмәгать туклануы предприятиесе урнаштыру өчен мәйданчыктан гыйбарәт махсус җиһазландырылган корылма, шул исәптән стационар предприятие карамагында;

и) күчереп йөртелә торган корылмалар (күчереп йөртелә торган сәүдә объектлары) – автокибетләр (автолавкалар, автоприцеплар), автокафе, изометрик сыешлыклар һәм цистерналар, арбалар, лотоклар һәм сәүдә эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен башка махсус җайланмалар;

к) стационар җәмәгать туклануы объекты карамагындагы сезонлы кафе – кулланучыларны тукландыру (яки аннан башка) буенча өстәмә хезмәт күрсәтү өчен билгеләнгән, ризык әзерләү өчен билгеләнмәгән, турыдан-туры җәмәгать туклануы предприятиесе тарафыннан җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган капиталь бинага, төзелмәгә, корылмага терәп салынган һәм расланган таләпләргә туры китереп җиһазландырылган вакытлы корылма (яки вакытлы конструкция);

л) мобиль сәүдә объекты – товарлар әзерләү, кую, демонстрацияләү, сатып алучыларга хезмәт күрсәтү һәм товарлар сатканда сатып алучылар белән исәп-хисап ясау өчен билгеләнгән махсус җиһазлар белән җиһазландырылган транспорт чарасыннан гыйбарәт сәүдә объекты. Әлеге объектларга механик транспорт чаралары һәм механик транспорт чаралары составында хәрәкәт итү өчен билгеләнгән транспорт чаралары.

## 3 бүлек. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыруга һәм аларның тышкы күренешенә таләпләр

6. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы

объектларын урнаштыру сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру схемасында (алга таба – урнаштыру схемасы) билгеләнгән урыннарда гамәлгә ашырыла.

7. Сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урам һәм юлларның кызыл линия чикләрендә урнаштырган очракта, аларны урнаштыру тротуар чикләрендә ныгытылган (асфальт түшәлгән) мәйданчыкта һәм тротуар буенча стационар булмаган сәүдә объектының һәм җәмәгать туклануы объектларының кырый элементыннан йөри торган юл читенә кадәр 1,5 метрдан ким булмаган иректе йөрү юлы калган шартларда гына мөмкин.

8. Сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштырганда җәяүлеләр йөрү өчен комачауламый торган уңайлы автотранспорт юлы күздә тотылырга тиеш.

Товар һәм җиһазларны бушату автомобильне тротуарга кертмәгән килеш гамәлгә ашырылырга тиеш.

9. Сезонлы стационар булмаган сәүдә объектлары һәм җәмәгать туклануы объектлары (урамга алып чыгып сату өчен күчереп йөртелә торган чаралардан тыш) янына суыткыч җиһазлар, өстәлләр, чатырлар һәм башка шундый объектлар урнаштыру рөхсәт ителми (Башкарма комитетның муниципаль хокукый актлары белән расланган сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларының һәм җәмәгать туклануы объектларының типовой проектларында шундый объектларны урнаштыру күздә тотылган очраклардан тыш).

10. Сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларына һәм җәмәгать туклануы объектларына таләпләр (тышкы күренеше, үлчәмнәре, мәйданы, конструктив схемасы һәм башка таләпләр) типовой проектлар белән билгеләнә.

## 4 бүлек. Сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру һәм эксплуатацияләү тәртибе

11. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру хокукы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру хокукына электрон аукционнар үткәрү нәтиҗәсендә алына.

12. Сезонлы кафе Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге милкендәге җир участогында яки дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә урнашкан очракта, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җәмәгать туклануы объектлары карамагында сезонлы кафелар урнаштыру хокукы гариза бирүчегә – җәмәгать туклануы предприятиесе стационар рәвештә урнаштырылган бүлмәләрнең, бинаның, төзелмәнең һәм корылманың хуҗасына яки арендаторына аукцион үткәрмичә, сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын һәм җәмәгать

тукланусы объектын урнаштыруга килешү (алга таба – сезонлы СБСО урнаштыруга килешү) төзегәннән соң бирелә.

Аукцион үткәрмичә сезонлы СБСО урнаштыруга килешү буенча түләү күләме, бәяләү эшчәнлеге турында Россия Федерациясе законнары нигезендә Башкарма комитет тарафыннан тәкъдим ителгән сезонлы СБСО урнаштыруга килешү төзү хокукының базар бәясен бәяләү турындагы хисапта каралганча билгеләнә.

13. Дәүләт җирләрендә, муниципаль җирләрдә һәм хокук чикләнмәгән җирләрдә стационар җәмәгать тукланусы объектлары карамагында сезонлы кафелар урнаштыру гариза бирүченең Башкарма комитет адресына юллаган язмача мөрәҗәгате буенча гамәлгә ашырыла. Гаризага түбәндәгеләр теркәлә:

1) стационар җәмәгать тукланусы объектына техник документлар күчермәсе (техник яки кадастр паспорты);

2) күчемсез милек объектына хокук билгеләүче документлар күчермәсе, шул исәптән:

- милек хокукын дәүләт теркәве турында таныклык яки янына сезонлы кафе урнаштыру күздә тотылган күчемсез милек объектына билгеләнгән тәртиптә аренда килешүе;

- юридик затлар өчен – юридик затларның Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә, устав, теркәлү турында таныклык;

- шәхси эшмәкәрләр өчен – теркәлү турында таныклык, паспортның барлык битләре.

14. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә стационар җәмәгать тукланусы объектлары карамагындагы сезонлы кафелар конструкциясе һәм аларның тышкы күренеше билгеләнгән тәртиптә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе белән килешенә һәм түбәндәгеләргә туры килергә тиеш:

- тиешле стационар җәмәгать тукланусы предприятиесе урнашкан объектның фасадлары һәм стилистикасының колорит чишелешенә;

- әйләнә-тирәдәге төзелешнең архитектура-шәһәр төзелеше чишелешенә;

- янәшә территорияне төзекләндерү үзенчәлекләренә, бу очракта стационар булмаган җәмәгать тукланусы объектларын урнаштыру урынының чикләре күрше бүлмәләр, биналар, төзелмәләр, корылмалар хуҗаларының һәм алардан файдаланучыларның хокукларын бозарга тиеш түгел.

15. Бер бинада, төзелмәдә, корылмада, конструкциядә төрле хуҗалык субъектларына караган берничә стационар җәмәгать тукланусы предприятиесе урнаштырылган очракта, аларның һәрберсе карамагында урнаштырылган сезонлы кафелар бердәм архитектура-художество чишелешендә (бердәм конструкция материаллары, үзара бәйле колорит) башкарылган булырга тиеш.

16. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендәге стационар җәмәгать тукланусы объектлары карамагындагы сезонлы

кафеларны төзекләндерү халыкның аз хәрәкәт итүче төркемнәре өчен уңайлылыгын тәэмин итү зарурлыгын исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

17. Стационар җәмәгать туклануы объектлары карамагындагы сезонлы кафеларның мәйданы, карамагында урнаштырыла торган стационар җәмәгать туклануы предприятиесе мәйданыннан артып китәргә тиеш түгел.

18. Стационар җәмәгать туклануы объектлары карамагындагы сезонлы кафеларны урнаштыру рөхсәт ителми:

- бина аркаларында, газоннарда, чәчәклекләрдә, балалар һәм спорт мәйданчыкларында, ял мәйданчыкларында, җәмәгать транспорты тукталышларында.

19. Стационар җәмәгать туклануы объектлары карамагындагы сезонлы кафеларны эксплуатацияләүгә таләпләр:

- сезонлы кафеларда ризыкның бер төрен дә әзерләү рөхсәт ителми;

- стационар җәмәгать туклануы объектлары карамагындагы сезонлы кафеларның мәйданын (территориясен) килүчеләрне урнаштыру өчен генә файдаланылырга мөмкин;

- сезонлы кафелар торак биналарга кертеп һәм терәп салынган бүлмәләрдә урнашкан стационар җәмәгать туклануы объектлары карамагында урнаштырылган очракта, эксплуатацияләгәндә ачы исләр бүлеп чыгара торган җиһазлардан файдалану рөхсәт ителми;

- төнлә 22 сәгатьтән 6 сәгатькә кадәр тавыш чыгара торган җайланмалар һәм тавыш көчәйтү җайланмаларынан файдалану, уен коралларында уйнау, җырлау, шулай ук гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны боза торган башка гамәлләр рөхсәт ителми;

- тәрәзәләргә яктылык нурлары турыдан-туры төшкән очракта, торак биналарның тәрәзәләре янында яктырту приборларыннан файдалану рөхсәт ителми.

20. Сезонлы СБСО урнаштыруга төзелгән килешү һәм килешү буенча тулысынча түләүне раслау сәүдә субъекты тарафыннан Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру (монтажлау) өчен нигез булып тора.

Сезонлы СБСО урнаштыруга килешү 180 көннән артмаган срокка төзелә.

21. Урнаштырылган сезонлы стационар булмаган сәүдә объектының һәм җәмәгать туклануы объектының килешүдә күрсәтелгән таләпләргә һәм типовой проектка туры килүе турында кабул итү комиссиясенең акты (алга таба – кабул итү комиссиясенең акты) сәүдә субъекты тарафыннан Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларыннан файдалану өчен нигез булып тора.

Кабул итү комиссиясенең составы муниципаль хокукый акт белән раслана.

22. Килешүдә күрсәтелгән таләпләргә һәм типовой проектка туры китереп урнаштырылган сезонлы стационар булмаган сәүдә объекты,

җәмәгать туклануы объекты сезонлы СБСО урнаштыруга килешү төзелгән датадан соң 15 (унбиш) көннән соңга калмый тикшерү өчен кабул итү комиссиясенә күрсәтелергә тиеш. Сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын, җәмәгать туклануы объектын тикшерү өчен, сәүдә субъекты Башкарма комитетка тиешле мөрәҗәгать юллый.

Сезонлы стационар булмаган сәүдә объекты, җәмәгать туклануы объекты, мөрәҗәгать кергәннән соң 5 (биш) эш көне эчендә кабул итү комиссиясе тарафыннан тикшерелә.

23. Сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын, җәмәгать туклануы объектын тикшерү нәтиҗәләре буенча, тикшерү көненнән соң 5 (биш) эш көне эчендә кабул итү комиссиясенең акты төзелә.

24. Сезонлы стационар булмаган сәүдә объекты, җәмәгать туклануы объекты кабул итү комиссиясенең актыннан башка эксплуатацияләнгән очракта, килешүнең гамәлдә булуы вәкаләтле орган тарафыннан берьяклы тәртиптә туктатыла, сезонлы стационар булмаган сәүдә объекты, җәмәгать туклануы объекты демонтажланырга тиеш була.

25. Җәмәгать туклануы предприятиеләренең эшчәнлеге әлеге өлкәдә гамәлдәге законнар, шул исәптән Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына карата өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2015 елның 6 мартындагы 10-ТРЗ санлы Законы белән регламентлаштырыла.

## 5 бүлек. Килешүнең гамәлдә булуын вакытыннан алда туктату тәртибе

26. Сезонлы СБСО урнаштыруга килешүнең гамәлдә булуы түбәндәге очракларда берьяклы тәртиптә вакытыннан алда туктатыла:

1) сәүдә субъекты тарафыннан законда билгеләнгән тәртиптә үз эшчәнлеген туктату;

2) Сезонлы СБСО урнаштыруга килешү шартларын бозу;

3) билгеләнгән срокта сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын, җәмәгать туклануы объектын кабул итү комиссиясе тарафыннан тикшерү өчен күрсәтмәү;

4) сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын, җәмәгать туклануы объектын кабул итү комиссиясенең актыннан башка файдалану;

5) сәүдә объекты тарафыннан, килешү шартларына туры китереп, килешү буенча түләү кертмәү;

6) Башкарма комитет тарафыннан билгеләнгән тәртиптә түбәндәге карарларны кабул итү:

- сезонлы стационар булмаган сәүдә объектының, җәмәгать туклануы объектының урнашуы күрсәтелгән эшләрне гамәлгә ашыруга комачаулаган очракта, автомобиль юлларын ремонтлау һәм (яки) реконструкцияләү кирәклеге турында;

- урам-юл челтәрен үстерү, шәһәр җәмәгать транспорты тукталышларын урнаштыру, бордюрлар белән җиһазландыру, парковка урыннары оештыру белән бәйле максатлар өчен, сезонлы стационар булмаган сәүдә объекты, җәмәгать туклануы объекты биләгән территориядән файдалану турында;
- региональ һәм муниципаль әһәмияткә ия капиталь төзелеш объектларын урнаштыру турында;

7) сезонлы стационар булмаган сәүдә объектыннан, җәмәгать туклануы объектыннан читтә суыткыч һәм күчереп йөртелә торган башка җиһазлар урнашыру. Әлеге таләп ташып сәүдә итү өчен күчереп йөртелә торган чараларга, шулай ук типовой карарда күздә тотылган очракларга кагылмый.

Сезонлы СБСО урнаштыруга килешүнең гамәлдә булуын вакытыннан алда туктаткан очракта, Башкарма комитетның вәкаләтле органы әлеге килешүнең гамәлдә булуын вакытыннан алда туктату турында карар кабул иткән вакыттан соң биш көн эчендә сәүдә субъектына тиешле белдерү кәгазе җибәрә.

27. Башкарма комитет инициативасы буенча сезонлы СБСО урнаштыруга килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылган очракта, әлеге килешүне өзү турында белдерү кәгазен алган көннән соң 5 (биш) көн эчендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объекты, җәмәгать туклануы объекты үз хисабына сәүдә субъекты тарафыннан демонтажланырга тиеш.

28. Сәүдә субъекты тарафыннан Башкарма комитетка эшчәнлеген туктату турында гариза бирелгән очракта, сезонлы СБСО урнаштыруга килешүнең гамәлдә булуы берьяклы тәртиптә вакытыннан алда туктатыла.

Шулай ук, сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын, җәмәгать туклануы объектын демонтажлау 14 (ундүрт) эш көне эчендә, сәүдә субъекты тарафыннан мөстәкыйль рәвештә һәм үз хисабына гамәлгә ашырыла.

## 6 бүлек. Сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын, җәмәгать туклануы объектларын демонтажлау

29. Сезонлы стационар булмаган сәүдә объекты, җәмәгать туклануы объекты, килешүнең гамәлдәге срогы тәмамланган датадан соң 14 (ундүрт) эш көне эчендә, сәүдә субъекты тарафыннан мәҗбүри рәвештә демонтажланырга тиеш.

30. Килешүнең гамәлдәге срогы чykканнан соң яки килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылганда, шулай ук сезонлы стационар булмаган сәүдә объекты, җәмәгать туклануы объекты билгеләнгән тәртиптәге рөхсәт документларыннан башка рөхсәтсез урнаштырылган очракта, сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын, җәмәгать туклануы объектын демонтажлау сәүдә субъекты тарафыннан ирекле рәвештә үтәлмәгән очракта, Башкарма комитет карары белән

расланган, капиталь төзелеш объекты булып саналмаган һәм законсыз урнаштырылган объектларны ачыклау, демонтажлау күчерү һәм саклау тәртибенә туры китереп, аны мәҗбүри рәвештә демонтажлау гамәлгә ашырыла.

## 7 бүлек. Йомгаклау нигезләмәләре

Сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру схемасын раслау, аңа үзгәрешләр кертү сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга килешү төзелгән һәм кабул итү комиссиясенең акты төзелгән стационар булмаган сәүдә объектларын, җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру урыннарын яңадан карап тикшерү өчен нигез булып тора алмый.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе — Г.К. Әхмәтова

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ГОРОДА НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Башкарма комитетның
2017 елның 18 апрелендәге
2342 нче карарына
2 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре территориясендә
сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру хокукына электрон аукцион оештыру һәм үткәрү турында нигезнамә

1. Гомуми нигезләмәләр

1. Яр Чаллы шәһәре территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру хокукына электрон аукцион оештыру һәм үткәрү турында әлеге нигезнамә (алга таба – нигезнамә) сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру хокукына электрон аукцион оештыру һәм үткәрү тәртибен билгели.

2. Нигезнамә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләти җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ санлы Федераль закон, Яр Чаллы шәһәре Уставы нигезендә эшләнде.

3. Сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру хокукына аукцион катнашучылар составы буенча ачык булып тора һәм электрон аукцион (алга таба – электрон аукцион) формасында үткәрелә.

4. Электрон аукцион предметы булып сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру хокукы (алга таба – лот) тора.

4. Оештыру-хокукый формасына, милекчелек формасына, урнашу урынына бәйсез рәвештә, стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру хокукына килешү (алга таба – Урнаштыруга килешү) төзүгә дәгъва итүче теләсә кайсы юридик зат яки шәхси эшмәкәр аукционда катнашучы булып тора ала.

5. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге исеменнән электрон аукцион үткәрүне оештыруны «Татарстан Республикасы дәүләт заказы, инвестиция эшчәнлеге һәм регионара элемтәләр агентлыгы» ДУП (алга таба – электрон мәйданчык операторы) белән берлектә Башкарма комитетның муниципаль заказ бүлеге йөзендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты (алга таба – вәкаләтле орган) гамәлгә ашыра.

6. Электрон аукцион үткәрү составы Башкарма комитетның 2016 елның 16 ноябрендәге 6061 нче карары белән расланган сатулар

оештыру һәм үткәрү буенча даими эшләүче комиссия (алга таба – комиссия) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Комиссия утырышында гомуми санының 50 процenttан ким булмаган әгъзалары катнашкан очракта, комиссия үз функцияләрен гамәлгә ашыруга хокуклы.

## 2 бүлек. Төп терминнар

7. Автоматлаштырылган система (АС) – электрон мәйданчык операторының аппарат-программа комплексы.

8. Аккредитация – гариза бирүчегә оператор регламенты таләпләре нигезендә операторның АС ябык өлешендә эшләү мөмкинлеге бирү.

9. Блокадалаучы субсчет – гариза бирүченең электрон аукционда катнашуын тәэмин итү максатында электрон мәйданчык операторының исәп-хисап счетына күчерелгән акчаларын блокадалау өчен файдаланыла торган гариза бирүче счетының субсчеты.

10. Килешү – электрон аукцион йомгаклары буенча яки башлангыч бәя буенча Россия Федерациясе Гражданнар кодексында, башка федераль законнарда һәм муниципаль хокукый актларда каралган тәртиптә, вәкаләтле орган һәм сәүдә субъекты тарафыннан төзелгән сезонлы стационар булмаган сәүдә объекты һәм җәмәгать туклануы объекты урнаштыру хокукына килешү.

11. Оператор – Россия Федерациясе территориясендә билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алынган, сайлап алынган электрон мәйданчыгы булган һәм анда электрон аукционнар үткәрүне тәэмин итүче, аның эшләп торуы өчен кирәкле программа-аппарат чараларына ия булган, оештыру-хокукый формасына, милекчелек формасына, урнашу урынына һәм капитал барлыкка килү урынына бәйсез юридик зат.

12. Рәсми сайт – вәкаләтле органның рәсми сайты http://nabchelny.ru/.

13. Электрон аукционда җиңүче – әлеге Нигезнамәдә билгеләнгән тәртиптә, стационар булмаган сәүдә объекты яки җәмәгать туклануы объекты урнаштыру хокукының иң югары бәясен тәкъдим иткән зат.

14. Заявкаларның беренче өлешен карап тикшерү беркетмәсе – комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана торган, гариза бирүчене аукционда катнашучы дип тану һәм сәүдә сессиясенә кертү турында мәгълүматлар булган беркетмә.

15. Электрон аукцион үткәрү беркетмәсе – электрон аукцион буенча сәүдә сессиясе үткәргәннән соң электрон мәйданчык операторы тарафыннан төзелгән беркетмә.

16. Йомгак ясау беркетмәсе – комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана торган, катнашучыны электрон аукционда җиңүче дип тану турында һәм электрон аукцион нәтиҗәләре турында мәгълүматлар булган беркетмә.

17. Вәкаләтле орган счеты – вәкаләтле органга күчерү өчен билгеләнгән һәм катнашучыларның акчаларын күчерү өчен, электрон

мәйданчыкта вәкаләтле органны теркәгәндә электрон мәйданчык операторы тарафыннан теркәлә торган счет.

18. Электрон аукционда катнашучы – оештыру-хокукый формасына, милекчелек формасына, урнашу урынына һәм капитал барлыкка килү урынына бәйсез юридик зат яки шәхси эшмәкәр.

19. Электрон аукционда катнашучы – электрон аукционда катнашуга заявка биргән һәм комиссия тарафыннан электрон аукционда катнашучы дип танылган гариза бирүче.

20. Электрон документ – мәгълүматны электрон-цифрлы рәвештә бирә торган документ, шул исәптән кәгазь документларның сканерланган версияләре.

21. Электрон цифрлы имза – электрон рәвештәге башка мәгълүматка (имзалана торган мәгълүматка) тоташтырыла торган яки әлеге мәгълүмат белән башкача бәйле булган һәм мәгълүматны имзалаучының затын билгеләү өчен файдаланыла торган электрон рәвештәге мәгълүмат.

## 3 бүлек. Вәкаләтле органның хокуклары

22. Вәкаләтле орган түбәндәгеләргә хокуклы:

1) бәяләү эшчәнлеге турында Россия Федерациясе законнары нигезендә, урнаштыруга килешү төзү хокукының базар бәясен бәяләү турындагы хисапка туры китереп, сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру хокукының башлангыч (минималь) бәясен билгеләргә;

2) аукцион документларын эшләргә һәм расларга;

3) гариза бирүчеләр тарафыннан заявканы тәэмин итүне кертү срогын һәм шартларын билгеләргә;

4) заявкаларны кабул итә башлау һәм аның тәмамлану датасын, электрон аукцион үткәрү датасын билгеләргә;

5) электрон мәйданчыкта электрон аукцион үткәрү турында мәгълүмати хәбәр әзерләүне һәм аны вәкаләтле органның рәсми сайтында урнаштыруны оештырырга;

6) мөрәҗәгать иткән датадан соң ике эш көне эчендә, гариза бирүченең запросы буенча аукцион документлары нигезләмәләренә аңлатмалар җибәрергә;

7) заявкалар кабул итүнең тәмамлану датасына кадәр биш эш көне эчендә аукцион документларына үзгәрешләр кертү турында карар кабул итәргә. Аукцион документларына кертелә торган үзгәрешләр электрон мәйданчыкта, рәсми сайтта урнаштырыла;

8) заявкалар кабул итүнең тәмамлану датасына кадәр биш эш көне эчендә, электрон мәйданчыкта, рәсми сайтта тиешле мәгълүмат урнаштырып, электрон аукцион үткәрүне кире кагарга;

9) электрон аукцион нәтиҗәләре турында мәгълүматны электрон мәйданчыкта, рәсми сайтта урнаштырырга. Гариза бирүче – электрон аукционда катнашучы электрон мәйданчыкта, рәсми сайтта урнаштырылган

аукцион документлары һәм аңа кертелгән үзгәрешләр белән танышмаган очракта, аның өчен вәкаләтле орган җаваплы түгел;

10) Россия Федерациясе законнары, «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләти җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ санлы Федераль законның 10 маддәсенең 4 бүлеге нигезендә шундыйлар рәтенә кертелгән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары арасында гына электрон аукцион үткәрү турында таләп куярга;

11) сезонлы стационар булмаган сәүдә объектлары һәм җәмәгать туклануы объектлары урнаштыру хокукына килешүләр төзергә;

12) сезонлы стационар булмаган сәүдә объектлары һәм җәмәгать туклануы объектлары урнаштыру хокукына килешү шартларының үтәлешенә контрольне гамәлгә ашырырга;

13) әлеге нигезнамәдә каралган һәм Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарына каршы килми торган башка кирәкле функцияләрне башкарырга.

## 4 бүлек. Электрон мәйданчык операторының вәкаләтләре

23. Электрон мәйданчык операторы түбәндәгеләргә хокуклы:

1) әлеге нигезнамә нигезендә электрон мәйданчык операторы хезмәтләре күрсәтергә;

2) Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында һәм әлеге нигезнамәдә билгеләнгән тәртип нигезендә электрон мәйданчыкның эшкә сәләтен һәм эшләвен тәэмин итәргә.

24. Электрон мәйданчык операторы түбәндәгеләргә бурычлы:

1) электрон аукцион үткәрүнең өзлексезлеген, электрон аукцион үткәрү өчен файдаланыла торган техник һәм программа чаралары эшенең ышанычлылыгын, электрон аукцион тәмамлану вакытына бәйсез рәвештә, аукционда катнашучыларның анда катнашуга бертигез мөмкинлеген тәэмин итәргә;

2) электрон мәйданчыкта аккредитация расланган вакыттан башлап, гариза бирүчегә электрон аукционда катнашуга кертелүне тәэмин итәргә;

3) электрон аукционнар үткәрү өчен, вәкаләтле органга шәхси кабинетка керүне тәэмин итәргә;

4) Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары һәм әлеге нигезнамә нигезендә, электрон мәйданчыкта электрон документлардан файдалануны тәэмин итәргә;

5) аукционда катнашуга заявкаларны (алга таба – заявкалар) һәм аларга теркәлгән документларны кабул итәргә;

6) заявкаларны исәпкә алырга һәм теркәргә;

7) катнашучыларның заявкаларына кагылышлы кабул ителгән карарлар турында аларга хәбәр итәргә;

8) электрон аукцион үткәрү беркетмәсе төзергә;

9) гариза бирүчеләр, аукционда катнашучылар һәм җиңүчеләр белән заявканы тәэмин итүне кабул итү һәм кире кайтару буенча исәп-хисаплар ясарга;

10) электрон мәйданчыкта техник житешсезлекләр килеп чыккан очракта, шундый житешсезлекләр турында, шулай ук яңа аукцион датасы һәм вакыты турында барлык гариза бирүчеләргә, электрон аукционда катнашучыларга һәм вәкаләтле органга хәбәр итәргә.

25. Әлеге нигезнамәдә каралган һәм Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарына каршы килми торган башка кирәкле функцияләрне башкарырга.

5 бүлек. Комиссиянең вәкаләтләре

26. Комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

1) теркәлгән документлар белән бергә электрон аукционда катнашуга заявкаларны карап тикшерергә;

2) гариза бирүчеләрне электрон аукционда катнашучылар дип тану турында яки гариза бирүчеләрне электрон аукционда катнашуга кертүне кирү кагу турында карарлар кабул итәргә һәм заявкаларның беренче карап тикшерү беркетмәсен рәсмиләштерергә;

3) электрон аукционда жиңүчене билгеләргә;

4) электрон аукцион йомгакларын чыгару беркетмәсен рәсмиләштерергә;

5) әлеге нигезнамәдә каралган һәм Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарына каршы килми торган башка кирәкле функцияләрне башкарырга.

6 бүлек. Гариза бирүчеләргә – электрон аукционда катнашучыларга таләпләр

27. Оештыру-хокукый формасына, милекчелек формасына, урнашу урынына, шулай ук капитал барлыкка килү урынына бәйсез, электрон мәйданчыкта аккредитация үткән юридик зат яки шәхси эшмәкәр электрон аукционда катнашучы булырга мөмкин.

28. Электрон аукционда катнашучылар Россия Федерациясе законнарында шундый катнашучыларга карата билгеләнгән таләпләргә туры килергә тиеш, шул исәптән:

1) юридик затның, шәхси эшмәкәрнең ликвидацияләнү факты булмау һәм юридик затны, шәхси эшмәкәрне банкрот дип тану һәм конкурс производствосы ачу турында арбитраж суд карарлары булмау;

2) заявка биргән көнгә Россия Федерациясенең Хокук бозулар турында кодексында каралган тәртиптә эшчәнлекне туктату факты булмау.

7 бүлек. Заявканы электрон аукционда катнашу өчен тәэмин итү һәм электрон аукцион адымы

29. Гариза бирүче, электрон аукционда заявка бирү өчен, электрон мәйданчыкта блокадалаучы субсчетка акча күчерә:

1) заявканы тәэмин итү сыйфатында – стационар булмаган сәүдә объектын яки җәмәгать туклануы объектын урнаштыру хокукының башлангыч (минималь) бәясеннән 50 процент күләмендә;

2) электрон аукционда катнашу өчен түләү сыйфатында – лотның башлангыч бәясенә бәйле рәвештә дифференцияләнеп, оператор тарафыннан билгеләнгән һәм электрон аукцион үткәрү турындагы хәбәрдә күрсәтелгән күләмдә.

30. Электрон аукцион адымы стационар булмаган сәүдә объектын яки җәмәгать туклануы объектын урнаштыру хокукының башлангыч (минималь) бәясенең 5 проценты күләмендә билгеләнә.

## 8 бүлек. Электрон аукцион үткәрү турында мәгълүмати хәбәр һәм аукцион документлары

31. Вәкаләтле орган әлеге нигезнамә нигезендә, мәгълүмати хәбәрне һәм электрон мәйданчыктагы электрон аукцион турында аукцион документларын http://old.zakazrf.ru адресы буенча урнаштыруны гамәлгә ашыра.

32. Электрон аукцион үткәрү турындагы мәгълүмати хәбәр, электрон аукционда катнашуга заявкалар бирү тәмамлану датасына кадәр кимендә 10 (ун) эш көне эчендә, вәкаләтле орган тарафыннан электрон мәйданчыкта урнаштырыла.

33. Аукцион документлары түбәндәге мәгълүматны үз эченә алырга тиеш:

1) вәкаләтле органның исеме, урнашу урыны һәм элемтә телефоны номеры;

2) гариза бирүчеләргә таләпләр;

3) объектның төре һәм мәйданы, аны урнаштыру урыны һәм срогы, махсуслашуы, сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын һәм җәмәгать туклануы объектын урнаштыру хокукының башлангыч (минималь) бәясе турында мәгълүматны үз эченә алган лот (лотлар) турында мәгълүматлар;

4) сезонлы стационар булмаган сәүдә объектының һәм җәмәгать туклануы объектының типовой проекты яки, булган очракта, күчмә корылмаларга таләпләр;

5) заявка эчтәлегенә, формасына, аны рәсмиләштерүгә һәм составына карата таләпләр;

6) заявканы тәэмин итү күләме, аны кертү срогы һәм тәртибе;

7) заявкаларны кабул итә башлау һәм аның тәмамлану датасы һәм вакыты;

8) заявкаларны карап тикшерү датасы һәм вакыты;

9) заявкаларны кире алу тәртибе һәм срогы;

10) электрон аукцион үткәрү датасы, вакыты һәм тәртибе;

11) аукцион документлары белән танышу тәртибе;

12) электрон аукцион үткәрелгәннән соң килешү төзү срогы;

13) сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын һәм җәмәгать туклануы объектын урнаштыру хокукына килешү проекты.

34. Вәкаләтле орган аукцион документларына үзгәрешләр кертү турында карар кабул итәргә хокуклы. Электрон аукцион предметын үзгәртү рөхсәт ителми. Вәкаләтле орган, шундый карар кабул ителгән көннән соң бер көн эчендә, ләкин заявкаларны кабул итү тәмамлану көненә кадәр биш эш көненнән дә соңга калмый, күрсәтелгән үзгәрешләрне электрон мәйданчыкта һәм рәсми сайтта урнаштыра.

35. Вәкаләтле орган электрон аукцион үткәрүне кире кагу турында карар кабул итәргә хокуклы. Вәкаләтле орган, шундый карар кабул ителгәннән соң бер көн эчендә, ләкин заявкаларны кабул итү тәмамлану көненә кадәр биш эш көненнән дә соңга калмый, кире кагу турындагы хәбәрне электрон мәйданчыкта урнаштыра.

## 9 бүлек. Заявкаларны кабул итү тәртибе

36. Электрон аукционда катнашуга заявкалар бирү бары тик электрон мәйданчыкта аккредитация алган затлар тарафыннан гына гамәлгә ашырыла. Гариза бирүченең электрон аукционнарда катнашуын тәэмин итү буенча операцияләр үткәрү өчен ачылган счетында, аның тарафыннан бирелгән заявкаларны тәэмин итү өчен җитәрлек акчасы булганда электрон аукционда катнашырга мөмкин.

37. Гариза бирүче тарафыннан электрон аукционга заявка ике өлештә һәм заявка бирелә торган һәр лотка карата аукцион документларында билгеләнгән форма буенча һәм срокларда бирелә. Заявканың һәр өлеше электрон цифрлы имза белән имзалана, ике өлеше дә бер үк вакытта бирелә.

38. Заявканың беренче өлеше түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

1) аукцион документлары нигезендә, Яр Чаллы шәһәре территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объекты һәм җәмәгать туклануы объекты урнаштыру хокукын сатып алуга ризалык;

2) электрон аукцион үткәрү датасы һәм электрон аукцион номеры турында мәгълүмат.

39. Заявканың икенче өлеше түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

1) гариза бирүче турында мәгълүматлар, шул исәптән юридик затның исеме һәм урнашу урыны яисә шәхси эшмәкәрнең фамилиясе, исеме, атасының исеме, почта адресы, ИНН, заявканың тәэмин ителешен кире кайтару һәм (яки) килешү төзү өчен банк реквизитлары, элемтә телефоны номеры; кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары арасында электрон аукцион үткәргәндә – гариза бирүченең күрсәтелгән категориягә кертелүен раслаучы мәгълүматлар;

2) сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын һәм җәмәгать туклануы объектын урнаштырганда, аукцион документларында күрсәтелгән мәҗбүри шартларны үтәүгә ризалык;

3) электрон аукцион үткәрү турындагы мәгълүмати хәбәр рәсми сайтта урнаштырылган датага кадәр алты ай эчендә юридик затларның

Бердәм дәүләт реестрыннан алынган өземтә күчермәсе; электрон аукцион үткәрү турындагы мәгълүмати хәбәр рәсми сайтта урнаштырылган датага кадәр алты ай эчендә шәхси эшмәкәрләрнең Бердәм дәүләт реестрыннан алынган өземтә күчермәсе; электрон аукцион үткәрү турындагы мәгълүмати хәбәр рәсми сайтта урнаштырылган датага кадәр алты ай эчендә алынган, юридик затның яки физик затның шәхси эшмәкәр буларак дәүләти теркәлү турында тиешле дәүләт законнары нигезендә рус теленә тәрҗемә ителгән документларның күчермәсе (чит ил затлары өчен);

4) затның гариза бирүче – юридик зат исеменнән эшләр башкаруга вәкаләтләрен раслаучы документ күчермәсе (физик затка ышаныч язуыннан башка гариза катнашучы исеменнән эш итәргә хокук бирә торган, физик затны вазыйфага билгеләү турында яки сайлау турында карар яисә билгеләү турында боерык күчермәсе (алга таба – җитәкче). Катнашучы исеменнән башка зат эш иткән очракта, заявкада, гариза бирүче исеменнән эш итү өчен, гариза бирүченең мөһере белән расланган һәм гариза бирүченең җитәчесе (юридик затлар өчен) яки җитәкченең вәкаләтле заты тарафыннан имзаланган ышаныч язуының күчермәсе булырга тиеш. Күрсәтелгән ышаныч язуы гариза бирүченең җитәкчесенең вәкаләтле заты тарафыннан имзаланган очракта, заявкада шул затның вәкаләтләрен раслаучы документның күчермәсе дә булырга тиеш;

5) гариза бирүченең оештыру документларының күчермәләре (юридик затлар өчен);

6) гариза бирүченең – юридик затның ликвидацияләнүе турында карар булмау, гариза бирүчене – юридик затны, шәхси эшмәкәрне банкрот дип тану турында һәм конкурс производствосы ачу турында арбитраж суд карары булмау турында, Россия Федерациясенең Хокук бозулар турында кодексында каралган тәртиптә гариза бирүченең эшчәнлеген туктату турында карарлар булмау турында гариза.

40. Заявка керү, электрон аукционда катнашуга заявканы тәэмин итү күләмендәге акчаларга карата, гариза бирүченең электрон аукционда катнашуын тәэмин итү буенча операцияләр үткәрү өчен ачылган счеты буенча операцияләрне блокадалау йөкләмәсе булып тора.

41. Гариза бирүче электрон аукционның һәр предметына (лотка) карата электрон аукционда катнашуга бер генә заявка бирергә хокуклы.

42. Электрон мәйданчык операторы түбәндәге очракларда заявкалар кабул итүне кире кага:

1) электрон аукционда катнашуга заявканы электрон документлар әйләнеше таләпләрен бозып бирү;

2) электрон аукционда катнашуга заявка биргән гариза бирүченең электрон аукционнарда катнашуын тәэмин итү буенча операцияләр үткәрү өчен ачылган счетында электрон аукционда катнашуга заявкасын тәэмин итәрлек күләмдә акчасы булмау;

3) гариза бирүче тарафыннан алдан бирелгән заявкалары кире алынмаган шартларда, бер үк гариза бирүче тарафыннан шул ук бер лотка карата электрон аукционда катнашуга ике яки берничә заявка бирелү.

Бу очракта, гариза бирүчегә әлеге лотка карата электрон аукционда катнашуга бирелгән барлык заявкалары да кире кайтарыла;

4) заявкалар бирү срогы тамамланганнан соң электрон аукционда катнашуга заявка алу;

5) гариза бирүчедән электрон аукционда катнашуга аккредитация кагыйдәләре бозылган заявка алу. Гариза бирүченең электрон аукционда катнашуын кире кагу өчен күрсәтелгән нигезләр исемлеге тулы булып тора.

43. Гариза бирүче заявкаларны кабул итү тәмамлану датасына кадәр теләсә кайсы вакытта электрон аукционда катнашуга заявкасын кире алырга хокуклы.

44. Электрон аукционда катнашуга заявка бирү, электрон аукцион йомгаклары буенча катнашучыны җиңүче дип таныган һәм аңа килешү төзү хокукы бирелгән очракта, гариза бирүченең электрон аукционда катнашуын тәэмин итү буенча операцияләр үткәрү өчен ачылган счетындагы акчаларны электрон аукционда катнашу өчен түләү сыйфатында исәптән чыгаруга ризалыгы булып тора.

45. Оператор, катнашуга бирелгән зявкаларның икенче өлешен карап тикшерү өчен, вәкаләтле орган адресына җибәргәнче үзара эш итүче якларга карата, электрон аукционда катнашуга заявка биргән гариза бирүчеләр мәгълүматларының конфиденциальлеген тәэмин итә.

46. Электрон аукционда катнашуга заявкалар бирү срогы тәмамлануга бер генә заявка бирелгән яки бер заявка да бирелмәгән очракта, электрон аукцион үтмәгән дип таныла.

47. Электрон аукционда катнашуга заявкаларны бирү, кире кайтару һәм кире алу нәтиҗәләре буенча электрон аукцион заявкалары реестрында бер генә заявка булган очракта, заявканың беренче өлеше турындагы мәгълүматлар белән берьюлы заявканың икенче өлеше дә җибәрелә.

## 10 бүлек. Заявкаларның беренче өлешен карап тикшерү

48. Комиссия заявкаларның беренче өлешен карап тикшерүне башкара, әлеге тикшерү срогы заявкалар бирү срогы тәмамланган көннән соң биш эш көненнән артырга тиеш түгел.

49. Заявкаларның беренче өлешен карап тикшерү тәмамланганнан соң, комиссия заявкаларның беренче өлешен карап тикшерү буенча язмача беркетмә формалаштыра, ул комиссиянең утырышта катнашкан барлык әгъзалары тарафыннан имзалана. Күрсәтелгән беркетмә һәр заявкага карата рөхсәт итү яисә рөхсәт итүне кире кагу турында карарларны үз эченә ала, беркетмә имзаланган көннең икенче көненнән дә соңга калмый операторга җибәрелә һәм электрон мәйданчыкта урнаштырыла.

50. Заявкаларны карап тикшерү беркетмәсе оператор тарафыннан электрон мәйданчыкта урнаштырылган вакыттан соң бер сәгать эчендә, барлык гариза бирүчеләргә дә заявкаларына карата кабул ителгән карарлар турында белдерү язуы җибәрелә.

51. Түбәндәге очракларда электрон аукцион үтмәгән дип таныла:

1) заявкалар бирү срогы тәмамлануга бер генә заявка бирелү;

2) заявкалар бирү срогы тәмамлануга бер заявка да бирелмәү;

3) комиссия тарафыннан барлык гариза бирүчеләрне дә электрон аукционда катнашуга кертүне кире кагу турында карар кабул итү.

Аукцион документларында ике һәм күбрәк лот каралган очракта, шундый карар кабул ителгән лотларга карата электрон аукцион үтмәгән дип танылa.

52. Әлеге нигезнамәнең 51 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән сәбәп буенча электрон аукцион үтмәгән дип танылган очракта, вәкаләтле орган яңа электрон аукцион үткәрү турында игълан итәргә хокуклы. Яңа электрон аукцион үткәрү турында игълан ителгән очракта, вәкаләтле орган аның шартларын үзгәртергә хокуклы.

53. Гариза бирүче, комиссия тарафыннан заявкаларның беренче өлешен карап тикшерү турында беркетмә рәсмиләштерелгәннән соң, электрон аукционда катнашучы статусы ала.

## 11 бүлек. Электрон аукцион оештыру һәм үткәрү

54. Электрон мәйданчыкта электрон аукцион мәгълүмати хәбәрдә күрсәтелгән көнне үткәрелә. Электрон аукцион үткәрелә башлау вакыты мәйданчык операторы тарафыннан Мәскәү вакыты буенча билгеләнә.

55. Электрон аукцион үткәрелә башлау вакытыннан соң катнашучы лот бәясе турында үз тәкъдимнәрен бирергә хокуклы.

56. Катнашучы электрон аукционның башка катнашучысы тарафыннан тәкъдим ителгән бәягә тигез лот бәясе турында тәкъдим керткән очракта, лот бәясе турында башка тәкъдимнәрдән алдарак кергән тәкъдим иң яхшысы дип танылa.

57. Электрон мәйданчыкта аукцион адымы стационар булмаган сәүдә объекты яки җәмәгать туклануы объекты урнаштыру хокукының башлангыч (минималь) бәясенең 5 (биш) процентын тәшкил итә.

58. Электрон аукцион үткәрү вакытында катнашучы тарафыннан бирелә торган лот турындагы һәр тәкъдим электрон цифрлы имза белән имзалана.

59. Электрон аукцион үткәргәндә лот бәясе турындагы тәкъдим тиененә кадәр төгәллек белән билгеләнә.

60. Электрон аукционда катнашучылар, агымдагы максималь тәкъдимне аукцион адымы зурлыгына арттыруны күздә тотучы лот бәясе турында тәкъдимнәр бирәләр.

61. Иң югары лот бәясен тәкъдим иткән катнашучы аукционда җиңүче дип танылa.

62. Соңгы тәкъдимне кабул иткәннән соң яки электрон аукцион башланганнан соң ун минут эчендә лот бәясе турында бер тәкъдим дә бирелмәгән очракта, әлеге лот буенча электрон аукцион автомат рәвештә төгәлләнә.

63. Электрон аукцион үткәрү беркетмәсе, электрон аукцион тәмамланганнан соң 30 (утыз) минут эчендә оператор тарафыннан электрон мәйданчыкта урнаштырыла.

64. Электрон аукцион үткәрү беркетмәсендә электрон мәйданчык адресы; электрон аукцион датасы, башлану һәм тәмамлану вакыты; сезонлы стационар булмаган сәүдә объекты һәм җәмәгать туклануы объекты урнаштыру хокукының башлангыч (минималь) бәясе; сезонлы стационар булмаган сәүдә объекты һәм җәмәгать туклануы объекты урнаштыру хокукының бәясе (лот бәясе) турында электрон аукционда катнашучылар тарафыннан бирелгән һәм, тәкъдимнәр кергән вакытны күрсәтеп, лот бәясе турында тиешле тәкъдимне ясаган электрон аукционда катнашучылар тарафыннан тапшырылган электрон аукционда катнашуга заявкаларга бирелгән тәртип номерлары күрсәтелеп, кими бару тәртибендә ранжирланган барлык максималь тәкъдимнәр күрсәтелә.

65. Электрон аукцион башланганнан соң ун минут эчендә электрон аукционда катнашучыларның берсе дә лот бәясе турында тәкъдим кертмәгән очракта, электрон аукцион үтмәгән дип таныла. Күрсәтелгән вакыт тәмамланганнан соң утыз минут эчендә оператор электрон аукцион үтмәгән дип тану турында беркетмәне (электрон мәйданчык адресын, электрон аукцион датасын, башлану һәм тәмамлану вакытын, лотның башлангыч (минималь) бәясен күрсәтеп) электрон сәүдә мәйданчыгында урнаштыра һәм аны вәкаләтле органга җибәрә.

## 12 бүлек. Электрон аукционда катнашуга заявкаларның икенче өлешен карап тикшерү һәм йомгак ясау

66. Электрон аукцион үткәрү беркетмәсен электрон мәйданчыкта урнаштырганнан соң бер сәгать эчендә, оператор электрон аукцион үткәрү беркетмәсен, электрон аукционда катнашучылар тарафыннан бирелгән электрон аукционда катнашуга заявкаларның икенче өлешен һәм аккредитацияләнгән катнашучылар реестрындагы мәгълүматларны вәкаләтле органга җибәрә.

67. Комиссия электрон аукционда катнашуга заявкаларның икенче өлеше аукцион документларында билгеләнгән таләпләргә туры килүне карап тикшерә.

68. Заявкаларның икенче өлешен, шулай ук аккредитацияләнгән катнашучылар реестрындагы мәгълүматларны карап тикшерүнең гомуми срогы электрон аукцион үткәрү беркетмәсен электрон мәйданчыкта урнаштырган көннән соң өч эш көненнән артырга тиеш түгел.

69. Комиссия заявкаларның икенче өлешен, электрон аукционда катнашуга 5 (биш) заявканың аукцион документларында каралган таләпләргә туры килүе турында карар кабул ителгәнче карап тикшерә. Заявкаларның икенче өлешен карап тикшерү, иң югары лот бәясен тәкъдим иткән электрон аукционда катнашучы тарафыннан бирелгән заявкадан

башлана һәм электрон аукционда катнашуга заявкаларның кими бару тәртибендә ранжирлануын исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

Электрон аукционда уннан ким катнашучы катнашкан һәм күрсәтелгән таләпләргә биштән ким заявка туры килгән очракта, комиссия аукционның барлык катнашучылары тарафыннан бирелгән заявкаларның икенче өлешен карап тикшерә. Әлеге заявкаларны карап тикшерү иң түбән лот бәясен тәкъдим иткән катнашучы тарафыннан бирелгән заявкадан башлана һәм заявкаларның ранжирлануын исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

70. Заявкаларның аукцион документларында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында карар кабул ителгән очракта, шулай ук аукционның барлык катнашучылары тарафыннан бирелгән заявкаларның икенче өлешен карап тикшерү нигезендә, бердән артык заявканың күрсәтелгән таләпләргә туры килүе турында карар кабул ителгән очракта, комиссия тарафыннан электрон аукционга йомгак ясау беркетмәсе рәсмиләштерелә һәм заявкаларны карап тикшерү тәмамланган көнне комиссиянең утырышта катнашкан барлык әгъзалары тарафыннан имзалана.

71. Беркетмә, ранжирланган һәм аукцион документларында билгеләнгән таләпләргә туры килү турында карар кабул итүгә мөнәсәбәтле электрон аукционда катнашуга заявкаларның тәртип номерлары турында мәгълүматларны, электрон аукционда катнашуга заявкаларының икенче өлеше карап тикшерелгән катнашучылар турындагы мәгълүматларны, кабул ителгән карарны дәлилләп, заявкаларның аукцион документларында билгеләнгән таләпләргә туры килүе яки туры килмәве турындагы карарны, заявканың аукцион документларында билгеләнгән таләпләргә туры килүе яки туры килмәве турында комиссиянең һәр әгъзасының карары турындагы мәгълүматларны үз эченә ала.

72. Иң югары лот бәясен тәкъдим иткән һәм заявкасы аукцион документларында билгеләнгән таләпләргә туры килгән электрон аукцион катнашучысы электрон аукционда җиңүче дип таныла.

73. Сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын һәм җәмәгать туклануы объектын урнаштыру хокукына килешү төзү хокукы, заявкасы аукцион документларында каралган таләпләргә һәм шартларга туры килгән очракта, бердәнбер заявка биргән затка, шулай ук, аукцион документларында каралган шартларда электрон аукционның бердәнбер катнашучысы дип танылган затка, сатулар үткәреп тормыйча, электрон аукцион үткәрү турында мәгълүмати хәбәрдә күрсәтелгән һәм стационар булмаган сәүдә объектын яки җәмәгать туклануы объектын урнаштыру хокукының башлангыч (минималь) бәясенә тигез булган сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын яки җәмәгать туклануы объектын урнаштыру хокукының бәясе белән тапшырылырга мөмкин.

74. Электрон аукционга йомгак ясау беркетмәсен электрон мәйданчыкта урнаштырган көннән соң биш эш көне эчендә, вәкаләтле орган электрон аукционның килешү төзүгә мөнәсәбәтле катнашучысы тарафыннан тәкъдим ителгән лот бәясен кертү юлы белән төзелгән килешү

проектын операторга җибәрә. Оператор кабул ителгән килешү проектын бер сәгать эчендә электрон аукционда җиңүчегә җибәрә.

75. Электрон аукционда җиңүче, килешү проектын алганнан соң биш эш көне эчендә, электрон мәйданчыкларның эш шартлары нигезендә, электрон аукционда катнашучы исеменнән эш итү хокукына ия затның көчәйтелгән электрон имзасы белән имзаланган килешү проектын электрон мәйданчык операторына җибәрә. Оператор, бер сәгать эчендә, электрон аукционда җиңүчедән алынган килешүне вәкаләтле орган адресына җибәрә.

76. Вәкаләтле орган, өч эш көне эчендә, электрон мәйданчыкларның эш шартлары нигезендә, вәкаләтле орган исеменнән эш итү хокукына ия затның көчәйтелгән электрон имзасы белән имзаланган килешүне операторга җибәрергә тиеш. Оператор бер сәгать эчендә килешүне электрон аукционда җиңүчегә җибәрә.

77. Әлеге нигезнамәнең 76 пункты нигезендә, оператор тарафыннан электрон аукционда катнашучыга килешү җибәрелгәннән соң килешү төзелгән дип санала.

78. Килешү төзелгән көннән соң бер эш көне эчендә, оператор аукционда катнашуны тәэмин итү өчен блокадаланган акчаларга карата, электрон аукционның барлык катнашучыларының блокадалаучы субсчетлары буенча операцияләрне блокадалауны туктата. Шулай ук оператор, җиңүче дип танылган электрон аукционда катнашучының блокадалаучы субсчетыннан, аукционда катнашкан өчен түләү сыйфатында, әлеге нигезнамәнең 29 пунктының 2 пунктчасында каралган күләмдә акчаларын ала.

79. Килешү төзелә:

1) электрон аукционда җиңүче белән;

2) аукционда җиңүче билгеләнгән срокта килешү төзүдән качарга тырышкан яки баш тарткан очракта – электрон аукционда җиңүче тарафыннан тәкъдим ителгән лот бәясеннән соң иң югары лот бәясен тәкъдим иткән электрон аукционның башка катнашучысы белән;

3) заявкасы һәм документлары комиссия тарафыннан аукцион документларына туры килә дип танылган бердәнбер гариза бирүче белән;

4) заявкаларның икенче өлешен карап тикшерү нәтиҗәләре буенча, комиссия тарафыннан бердәнбер катнашучы дип танылган электрон аукционда катнашучы белән.

80. Әлеге нигезнамәнең 79 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән очракта, электрон аукционда җиңүче килешү төзү хокукын югалта һәм заявка тәэмин ителеше аңа кире кайтарылмый, ә оператор тарафыннан вәкаләтле орган счетына күчерелергә тиеш була.

81. Әлеге нигезнамәнең 80 пунктында күрсәтелгән затлар лот буенча килешү төзүдән качарга тырышкан очракта, әлеге лот буенча электрон аукцион үтмәгән дип таныла һәм вәкаләтле лотны сатуга кабат куярга хокуклы.

## 13 бүлек. Заявка тәэмин ителешен кире кайтару тәртибе

82. Заявкаларны тәэмин итү сыйфатында гариза бирүчеләр тарафыннан кертелгән акчалар оператор тарафыннан биш эш көне эчендә кире кайтарыла:

1) гариза бирүчеләргә – электрон аукцион үткәрүне кире кагу турындагы хәбәр электрон мәйданчыкта урнаштырылган көннән башлап;

2) заявкасын кире алу сәбәпле, гариза бирүчегә – заявкаларны кабул итү тәмамланган көнгә кадәр;

3) электрон аукцион үтмәгән дип танылган очракта, гариза бирүчеләргә – заявкаларның беренче өлешен карап тикшерү беркетмәсе электрон мәйданчыкта урнаштырылган көннән башлап;

4) электрон аукционда катнашучыларга – электрон аукцион йомгакларын чыгару беркетмәсен электрон мәйданчыкта урнаштырган көннән башлап, җиңүче һәм җиңүче тарафыннан тәкъдим ителгәннән соң, иң югары лот бәясен тәкъдим иткән катнашучыдан тыш;

5) электрон аукционда җиңүче тарафыннан тәкъдим ителгәннән соң, иң югары лот бәясен тәкъдим иткән электрон аукционда катнашучыга – җиңүче белән килешү төзелгәннән соң.

83. Электрон аукционда җиңүчене яки җиңүче тарафыннан тәкъдим ителгәннән соң, иң югары лот бәясен тәкъдим иткән электрон аукционда катнашучыны килешү төзүдән баш тарткан дип таныган очракта, әлеге катнашучылар тарафыннан әлеге нигезнамәнең 29 пунктының 1 пунктчасы нигезендә, заявкаларны тәэмин итү сыйфатында кертелгән акчалар кире кайтарылмый, ә оператор тарафыннан вәкаләтле орган счетына күчерелә.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Г.К. Әхмәтова

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы объектларны һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру тәртибе турында нигезнамәгә кушымта

Сезонлы стационар булмаган сәүдә объектының
һәм җәмәгать туклануы объектының сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын һәм җәмәгать туклануы объектын урнаштыру хокукына килешүдә күрсәтелгән таләпләргә һәм типовой проектка туры килүе турында
кабул итү комиссиясенең акты

Яр Чаллы шәһәре «____» _________20___ ел

Кабул итү комиссиясе түбәндәге составта:

комиссия рәисе:

____________________________________________________________________

________________________________________________________________,

(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе вәкиле)

комиссия әгъзалары:

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________,

(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе вәкиле)

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________,

(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының архитектура, шәһәр төзелеше һәм торакны үстерү идарәсе вәкиле)

____________________________________________________________________

__________________________________________________________________,

(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының район (Автозавод, комсомол, Үзәк) Хакимияте вәкиле)

____________________________________________________________________

(сәүдә субъекты)

билгеләде:

1. Сәүдә субъекты тарафыннан

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

(юридик зат яки шәхси эшмәкәр күрсәтелә)

кабул итүгә сезонлы стационар булмаган сәүдә объекты/җәмәгать туклануы объекты тәкъдим ителде

___

___

(тибы)

___

(алга таба – Объект) гамәлгә ашыру өчен

___

___

(эшчәнлек төре, реализацияләнә торган товарлар, күрсәтелә торган хезмәтләр төркеме)

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру схемасы нигезендә адрес ориентиры буенча гомуми мәйданы ______ кв. м булган участокта:

___.

(объектның урнашу урыны)

2. Эшләр түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырылды:
- сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын/җәмәгать туклануы объектын урнаштыру хокукына килешү ___________ № ___;
- типовой (килешенгән) проект

___

___.

(исеме, архитектура чишелешенең характеристикасы күрсәтелә)

3. Кабул итүгә тәкъдим ителгән Объект түбәндәге күрсәткечләргә ия:
а) Объект мәйданы – ______ кв. м;
б) Объектның иңе/буе – ______ м;
в) секцияләр саны (булган очракта) – ______ берәмлек;
г) җәмәгать туклануы объекты өчен утырту урыннарының саны ______берәмлек;
д) Объект эшләнгән материал – ________________;
е) өстәмә күрсәткечләр: ___________________________________.
Ачыкланган кимчелекләр буенча кабул итү комиссиясенең тәкъдимнәре:

___

___

___

___

4. Әлеге акт күчемсез милеккә һәм аңа бәйле килешүләр төзүгә хокукларның Бердәм дәүләт реестрында күчемсез милек объекты сыйфатында Объектка хокукны теркәү мөмкинлеген тыя.

Кабул итү комиссиясенең карары:
Кабул итүгә тәкъдим ителгән Объект түбәндәгеләрдә күрсәтелгән таләпләргә туры килә (туры килми)

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________,

(документларның реквизитлары күрсәтелә)

һәм эксплуатацияләүгә әзер (әзер түгел).

Кабул итү комиссиясе рәисе:

___________________________________________________________________________

(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе вәкиле)

____________________/____________________/

(имза) (Ф.И.А.и.)

Кабул итү комиссиясе әгъзалары:

___________________________________________________________________________

(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының жир һәм милкәти мөнәсәбәтләр идарәсе вәкиле)

____________________/____________________/

(имза) (Ф.И.А.и.)

___________________________________________________________________________

(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе вәкиле)

____________________/____________________/

(имза) (Ф.И.А.и.)

___________________________________________________________________________

(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының район (Автозавод, комсомол, Үзәк) Хакимияте вәкиле)

____________________/____________________/

(имза) (Ф.И.А.и.)

___________________________________________________________________________

(сәүдә субъекты)

____________________/____________________/

(имза) (Ф.И.А.и.)

Акт ике нөсхәдә төзелде, берсе – сәүдә субъекты өчен, икенчесе – Башкарма комитет өчен.